**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**О праздновании 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая**

Учитывая выдающийся вклад великого татарского поэта Габдуллы Тукая в отечественную культуру, в ознаменование 140-летия со дня его рождения **постановляю:**

1. Провести в апреле 2026 года в Республике Татарстан торжественные мероприятия, посвященные празднованию 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая.

2. Образовать организационный комитет по подготовке и проведению празднования 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая.

3. Утвердить Положение об организационном комитете по подготовке и проведению празднования 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая (приложение № 1) и его состав (приложение № 2).

4. Кабинету Министров Республики Татарстан в 45-дневный срок разработать с учетом предложений организационного комитета по подготовке и проведению празднования 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая и утвердить республиканский план основных мероприятий по подготовке и проведению празднования 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая, а также обеспечить контроль за его реализацией.

5. Республиканскому агентству по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» обеспечить широкое освещение празднования 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая в средствах массовой информации.

6. Предложить органам местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, организациям и общественным объединениям принять активное участие в подготовке и проведении мероприятий, посвященных празднованию 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая.

7. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
26 декабря 2025 года
№ 1089

Приложение № 1
к Указу Раиса
Республики Татарстан
от «26» декабря 2025 года
№ 1089

**Положение**
**об организационном комитете по подготовке и проведению празднования 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая**

1. Организационный комитет по подготовке и проведению празднования 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая (далее – организационный комитет) образован в целях подготовки и проведения в Республике Татарстан мероприятий, посвященных 140-летию со дня рождения Габдуллы Тукая, а также обеспечения координации деятельности органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления), организаций и общественных объединений, участвующих в реализации вышеуказанных мероприятий.

2. Организационный комитет в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан, иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

3. Основными задачами организационного комитета являются:

а) разработка предложений в республиканский план основных мероприятий по подготовке и проведению празднования 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая (далее – План мероприятий);

б) обеспечение координации деятельности органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений по решению задач, связанных с исполнением Плана мероприятий;

в) рассмотрение вопросов исполнения Плана мероприятий и разработка предложений по его корректировке.

4. Организационный комитет в целях реализации стоящих перед ним задач имеет право:

а) запрашивать и получать в соответствии с законодательством от органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных

органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений информационные материалы по вопросам, относящимся к компетенции организационного комитета;

б) создавать в установленном порядке временные рабочие группы для решения вопросов, относящихся к компетенции организационного комитета;

в) приглашать на свои заседания руководителей органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений.

5. Состав организационного комитета утверждается Раисом Республики Татарстан.

6. В состав организационного комитета входят председатель организационного комитета, заместители председателя организационного комитета и члены организационного комитета, которые принимают участие в его работе на общественных началах.

7. Заседания организационного комитета проводятся по мере необходимости, но не реже одного раза в год.

8. Заседания организационного комитета ведет председатель организационного комитета или по его поручению один из заместителей председателя организационного комитета.

9. Повестку дня заседаний, место и порядок их проведения определяет председатель организационного комитета.

10. Заседание организационного комитета считается правомочным, если в нем принимают участие более половины его членов.

11. Решения организационного комитета принимаются большинством голосов присутствующих на заседании членов организационного комитета. При равенстве голосов голос председательствующего на заседании организационного комитета является решающим. В случае отсутствия члена организационного комитета на заседании он вправе изложить в письменной форме свое мнение по рассматриваемым вопросам, которое подлежит обязательному приобщению к протоколу заседания организационного комитета.

12. По результатам рассмотрения вопросов на заседании организационного комитета принимаются решения, которые оформляются протоколом. Протокол заседания организационного комитета подписывается председательствующим.

13. Решения, принимаемые организационным комитетом, доводятся до сведения заинтересованных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления, организаций и общественных объединений.

14. На основании решений организационного комитета могут разрабатываться проекты актов Раиса Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан.

15. Материально-техническое, документационное и информационное обеспечение деятельности организационного комитета осуществляет Аппарат Кабинета Министров Республики Татарстан.

Приложение № 2
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от « 26 » декабря 2025 года

№ 1089

**Состав**
**организационного комитета по подготовке и проведению празднования 140-летия со дня рождения Габдуллы Тукая**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, председатель организационного комитета |
| Сафаров Асгат Ахметович | Руководитель Администрации Раиса Республики Татарстан, заместитель председателя организационного комитета |
| Шайхразиев Василь Габтелгаязович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, заместитель председателя организационного комитета |
| Низамова Ляйсан Гаптелхановна | начальник Управления культуры и развития языков народов Республики Татарстан Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан, секретарь организационного комитета |
| Айзатуллин Марат Мансурович | министр строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Аминов Ильшат Юнусович | генеральный директор акционерного общества «Телерадиокомпания «Новый Век», депутат Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию) |
| Ахметшин Равиль Калимуллович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – Полномочный представитель Республики Татарстан в Российской Федерации |

| | |
|---|---|
| Аюпова<br>Ирада Хафизяновна | министр культуры Республики Татарстан |
| Батуллин<br>Роберт Мухлисович | народный писатель Республики Татарстан (по согласованию) |
| Габдрахманова<br>Гульнара Закариевна | председатель Государственного комитета Республики Татарстан по архивному делу |
| Галиуллин<br>Рустем Гусманович | генеральный директор общества с ограниченной ответственностью «Татарское книжное издательство» (по согласованию) |
| Губайдуллин<br>Экзам Саматович | председатель Ассоциации «Совет муниципальных образований Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Зайдуллин<br>Ркаил Рафаилович | председатель региональной общественной организации «Союз писателей Республики Татарстан» Общероссийской общественной организации «Союз писателей России», депутат Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию) |
| Зарипов<br>Айрат Ринатович | председатель Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по образованию, культуре, науке и национальным вопросам (по согласованию) |
| Кадыров<br>Азат Рифгатович | министр по делам молодежи Республики Татарстан |
| Коробченко<br>Олег Владимирович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан |
| Леонов<br>Владимир Александрович | министр спорта Республики Татарстан |
| Метшин<br>Ильсур Раисович | глава муниципального образования города Казани (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Минниханов Рифкат Нургалиевич | президент государственного научного бюджетного учреждения «Академия наук Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Мухаметзянов Рауфаль Сабирович | директор государственного бюджетного учреждения «Татарский академический государственный театр оперы и балета имени Мусы Джалиля» (по согласованию) |
| Мухарлямов Руслан Робертович | заместитель Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан – руководитель Департамента Раиса Республики Татарстан по вопросам внутренней политики |
| Начвин Илья Сергеевич | министр цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан |
| Нутфуллин Рамиль Рашитович | глава муниципального образования «Балтасинский муниципальный район» (по согласованию) |
| Салимгараев Айдар Саитгараевич | руководитель Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» |
| Сафин Ленар Ринатович | ректор федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет» (по согласованию) |
| Файзрахманов Айрат Шамилевич | исполняющий обязанности генерального директора государственного бюджетного учреждения культуры «Национальный музей Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Файзуллин Равиль Габдрахманович | народный поэт Республики Татарстан (по согласованию) |
| Хадиуллин Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Халиков Ильгиз Ильдарович | директор обособленного структурного подразделения государственного научного бюджетного учреждения «Академия наук Республики Татарстан» «Институт языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Ханифов Фарит Мударисович | министр транспорта и дорожного хозяйства Республики Татарстан |
| Хисамиев Рустем Шагитович | глава муниципального образования «Атнинский муниципальный район» (по согласованию) |
| Хисамутдинов Алмаз Гаптраупович | глава муниципального образования «Арский муниципальный район» (по согласованию) |
| Шакиров Данис Фанисович | первый заместитель председателя Национального Совета Всемирного конгресса татар – руководитель Исполнительного комитета Всемирного конгресса татар, депутат Государственного Совета Республики Татарстан (по согласованию) |
| Шаяхметов Шамиль Ильгамович | Постоянный представитель Республики Татарстан в городе Санкт-Петербурге и Ленинградской области |

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итү турында**

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның илебез мәдәниятенә гаять зур өлеш кертүен исәпкә алып, аның тууына 140 ел тулуны билгеләп үтү йөзеннән **карар бирәм:**

1. 2026 елның апрелендә Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган тантаналы чаралар уздырырга.

2. Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә.

3. Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетының тәкъдимнәрен исәпкә алып, 45 көн эчендә Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча республикакүләм төп чаралар планын расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм җәмәгать берләшмәләренә Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашуны тәкъдим итәргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 26 декабрь
№ 1089

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның « 26 » декабрендәге
1089 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты турында
нигезләмә**

1. Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуга багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру, шулай ук югарыда күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруда катнаша торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү максатында төзелде.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча республикакүләм төп чаралар планына (алга таба – Чаралар планы) кертү өчен тәкъдимнәр эшләү;

б) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Чаралар планын үтәүгә бәйле бурычларны хәл итү буенча эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

в) Чаралар планын үтәү буенча тәкъдимнәр эшләү мәсьәләләрен карап тикшерү һәм аңа үзгәрешләр кертү.

4. Үз алдында торган бурычларны үтәү максатында Оештыру комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрдән законнар нигезендә оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

б) оештыру комитеты компетенциясенә кергән мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә вакытлы эш төркемнәре оештырырга;

в) үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен чакырырга.

5. Оештыру комитетының составы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

6. Оештыру комитеты составына оештыру комитеты рәисе, оештыру комитеты рәисе урынбасарлары һәм оештыру комитеты әгъзалары керә, алар комитет эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша.

7. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен, ләкин кимендә елына бер тапкыр үткәрелә.

8. Оештыру комитеты утырышларын оештыру комитеты рәисе яки аның кушуы буенча оештыру комитеты рәисе урынбасарларының берсе алып бара.

9. Утырышларның көн тәртибен, үткәрү урынын һәм тәртибен оештыру комитеты рәисе билгели.

10. Оештыру комитеты утырышы, анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашкан очракта, гамәлгә хокуклы дип санала.

11. Оештыру комитеты карарлары утырышта катнашкан оештыру комитеты әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны бертигез булганда, оештыру комитеты утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала. Утырышта катнашмаган очракта, оештыру комитеты әгъзасы карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә белдерергә хокуклы. Ул мәҗбүри рәвештә оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә теркәлергә тиеш.

12. Оештыру комитеты утырышында мәсьәләләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Оештыру комитеты утырышының беркетмәсенә утырышта рәислек итүче кул куя.

13. Оештыру комитеты кабул иткән карарлар кызыксыну белдергән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә җиткерелә.

14. Оештыру комитеты карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары проектлары әзерләнергә мөмкин.

15. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник яктан, документлар һәм мәгълүмат белән тәэмин итүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты башкара.

___________

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның «26» декабрендәге
1089 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, оештыру комитеты рәисе |
| Сәфәров Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Шәйхразыев Васил Габделгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Низамова Ләйсән Габделхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы, оештыру комитеты секретаре |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Әминов Илшат Юныс улы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Әхмәтшин Равил Кәлимулла улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиле |

| | |
|---|---|
| Әюпова<br>Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Батуллин<br>Роберт Мөхлис улы | Татарстан Республикасының халык язучысы (килешү буенча) |
| Габдрахманова<br>Гөлнара Зәкәрия кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Галиуллин<br>Рөстәм Госман улы | «Татарстан китап нәшрияты» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин<br>Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Зәйдуллин<br>Ркаил Рафаил улы | «Россия Язучылар берлеге» гомумроссия җәмәгать оешмасының «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» төбәк җәмәгать оешмасы рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Кадыйров<br>Азат Рифгать улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Коробченко<br>Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Леонов<br>Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Миңнеханов<br>Рифкать Нургали улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президенты (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов<br>Рәүфәл Сабир улы | «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Мөхәрләмов<br>Руслан Роберт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |
| Начвин<br>Илья Сергеевич | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Нотфуллин<br>Рамил Рәшит улы | «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин<br>Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Фәйзрахманов<br>Айрат Шамил улы | «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе генераль директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Фәйзуллин<br>Равил Габдрахман улы | Татарстан Республикасының халык шагыйре (килешү буенча) |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |

| | |
|---|---|
| Халиков<br>Илгиз Илдар улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсе директоры (килешү буенча) |
| Хәнифов<br>Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Хисамиев<br>Рөстәм Шаһит улы | «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Хисаметдинов<br>Алмаз Габдерәүф улы | «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Шакиров<br>Данис Фәнис улы | «Бөтендөнья татар конгрессы» Халыкара Берлеге Милли Шурасы рәисенең беренче урынбасары – «Бөтендөнья татар конгрессы» Халыкара Берлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шәяхмәтов<br>Шамил Илһам улы | Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле |

___